# ТАТАР ТЕЛЕН САКЛАУ ҺӘМ ҮСТЕРҮ КОМИССИЯСЕНӘ БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР ЯШЬЛӘРЕ ФОРУМЫ СОВЕТЫННАН ТӘКЪДИМНӘР:

**МӘГАРИФ:**

1) Татар телендә сыйфатлы тәрбия биргән балалар бакчалары челтәрен булдыру, булган татар балалар бакчаларын татар телле тәрбиягә кайтару. Урыс телле балалар бакчаларында татар телле төркемнәр булдыру.
   - Аларның эшчәнлеген контрольгә алу, хакимият һәм җәмәгатьчелек тарафыннан аларның эшчәнлеген күзәтү. Критерийлар системасын булдыру.
   - Әлеге балалар бакчаларын күптелле, заманча алымнарны куллана алган тәрбиячеләр белән тәэмин итү, әзерләү системасын ныгыту.
   - Татар телендә белем һәм тәрбия бирә торган балалар бакчалары һәм хосусый балалар үзәкләре өчен махсус грантлар булдыру.
   - Мәктәпкәчә балалар өчен татар телендә уенчыклар, китаплар, заманча әсбаплар, мультимедиа чаралар, өстәл уеннарын булдыру эшен системага салу.
   - Ата-аналар белән балаларын татар төркемнәрендә тәрбияләүнең өстенлеген аңлату эшләрен оештыру. Район һәм иҗтимагый оешмалар белән бергә татар бакчаларының әһәмиятен аңлату, бу идеяне популярлаштыру.
   - Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында өстәмә татар телле түгәрәкләр оештыру (бию, җыр, робототехника, экология, аш-су һ.б.)
2) Татар телен мәктәпләрдә дәүләт теле буларак укытуга ачыклык кертү. Татар телен дәүләт теле буларак укытуны гамәлгә кертү эшен дәвам итү. Аны федераль стандартларга керттерү.
3) Татар телен нәтиҗәле һәм заманча укыту системасын камилләштерү.
   - “Сәлам” дәреслеге мисалында яңа буын татар теле дәреслекләрен төзү эшен җәелдерү. Көндәшлек принципларына таянып, бу эшкә төрле автор коллективларын җәлеп итү.
   - Татар теле укытучыларын әзерләүдә һәм квалификацияләрен арттыруда заманча һәм дөньяның алдынгы технологияләрен куллану. Татар теле укытучылары (Татарстанда һәм чит төбәкләрдә) өчен грантлар системасын һәм мотивацион программа булдыру.
   - Татар теле укытучыларның санын барлау.
4) Татар телендә белем биргән мәктәпләрне ачыклау, укытуга һәм тәрбия чараларына бәйсез мониторинг, анализ ясау. Татар телендә белем бирә торган укытучыларның санын һәм мәктәпләргә тәэмин ителешен тикшерү.
   - Мәктәпләрне тиешле дәреслекләр, өстәмә, заманча әсбаплар белән тәэмин итү.
   - Ике дәүләт телендә белем бирә торган укытучыларга грантлар рәвешендә финанс ярдәм күрсәтү.
   - Татарча укытмаган татар мәктәпләрен татар теленә кайтару яки полилингваль методикаларга күчерү.

- Муниципаль берәмлекләргә ел саен урыс телле мәктәпләр белән беррәттән татар яки полилингваль мәктәпләрен ачу таләбен кую.

5) Бердәм дәүләт имтиханын татарча тапшыру мөмкинлеген таләп итү. Комиссия бу мәсьәләне күтәрергә, федераль оешмалар белән аралашырга тиеш.
6) Татарстан югары уку йортларында татар төркемнәрен ачу эшен башлау, татар телендә югары белемне алу мөмкинлеген булдыру.
   - Милли университет концепциясен тормышка ашыру.
   - Татар телендә югары белем алган студентларга өстәмә стипендия булдыру.
   - Киләчәктә татар телендә эшчәнлек алып бара алган кадрларны әзерләү системасын булдыру (укытучылар, журналистлар, милли интеллигенция).

   Яшьләр форумының югары белем турында махсус конценпциясе бар
7) Татар телен үстерү фондын булдыру. Фонд даими рәвештә татар телен үстерү проектларын финансларга, ярдәм күрсәтеп торырга тиеш. Югарыда әйтелгән грантлар һәм стипендияләр шул фондтан финанслана ала.
8) Ата-аналарда татар телен популярлаштыру, татар телле белем алуның өстенлекләрен аңлату эшен алып бару. Матбугат чараларына моның турында дәүләт күрсәтмәсен (гос.задание) тапшыру.
9) Татар телендә укыта торган дистанцион (өйдә укый торган) мәктәп системасы. Татарстандагы берничә көчле татар мәктәбенә беркетелү мөмкинлеге (мисал өчен, Казанның 2нче татар гимназиясе, сәләтле балалар өчен Актаныш гимназиясе). Рекрутинг механизмын булдыру, татар оешмалары аша системаны эшләтү.
10) Мәктәптән соң укучыларга татар телен белү сертифкатын алу мөмкинлеген булдыру. Югары уку йортларына кергәндә татар телендә имтихан тапшыру өчен өстәмә баллар бирү.
11) Татар телен онлайн өйрәнү платформаларын булдыру, күбәйтү, сыйфаты өстендә эш. “Ана теле” һәм башка булган проектларны көчәйтү, методикасын камилләштерү, маркетинг өстендә эшләү.
12) Чит төбәкләр, илләрдән балаларны Татарстанга китерү, гаиләләрдә яшәтү, лагерь программасы.

**ИҖТИМАГЫЙ КИҢЛЕК:**

13) Татарстанда икетеллелекне даими мониторинг эшен алып бару. Элмә такталарының ике дәүләт телендә булуын тәэмин итү. 2022 елга кадәр Казанның тарихи үзәгендә барлык элмә такаталары татар телендә дә башкарылырга тиеш.
14) Дәүләт оештыра торган чараларда һәм социаль челтәрләрдә алып барылган рәсми аккаунтлар, барлык презентацион материаллар, баннерлар татарча да булырга тиеш. Чыгышлар, докладларның кимендә 20%-ы татарча булырга тиеш.
15) Кафелар, кунакханәләр, кибетләр һәм халыкка хезмәт күрсәткән башка төрле оешмаларны татар телле сервиска өйрәтү системасын булдыру. Моның өчен алар белән аңлату эшен алып бару, бушлай кыска тел тренингларын оештыру.
16) Барлык эре ритейллар белән татар телендә мәгълүмат белән эш итәргә өйрәтү (Пятерочка мисалында).
17) Җәмәгатьчелек бн эш иткән дәүләт хезмәткәрләре өчен татар теленнән имтихан булдыру

18) Татар теле үзәген булдыру. Функцияләре: пиар, акцияләр, бизнеска тәрҗемә итү, колл-центр, социаль роликлар төшерү, тел клубларын оештыру, Татарстанның югары уку йортларында тел көне оештыру, студентлар клубы оештырырга ярдәм итү, экскурсияләргә йөртү, ютуб каналлар алып бару, кечкенә медиа оештырырга ярдәм итү, блогингны үстерү, татарча контентны тарату. Татар телен пропагандалау хәрәкәтен булдыру. Татар телен өйрәнү өчен мотивация өстендә системалы эш. Грантлар системы: һәвәскәрләргә проектларын үстерү мөмкинлеге, татар теле стартаплары.
19) Татарстанда милли өлкәдә бирелә торган грантларда ачыклык принцибын кертү:
    - грантларга гаризалар бирү һәм аларны сайлап алу процедурасын, отчетларын ачык рәвештә күрсәтү.
    - элек тапшырылган грантларга анализ ясау, нәтиҗәлелеген барлау. Алга таба приоритет фольклор чараларга түгел, белем бирү, мәгариф, милли үзаң үстерү проектларына бирелергә тиеш.
20) Татар милләтен өйрәнү буенча масштаблы социологик, демографик тикшеренүләр үткәрү. Татар милләте проблемнарын өйрәнүче экспертлар үзәкләре һәм аналитик институтлар булдыру (мәсәлән, “Институт стратегических исследований”).
21) Тел хокукларын яклау үзәген оештыру. Бу үзәк Татарстанда һәм чит төбәкләрдә яшәүче татарларның милли хокукларын бозуга каршы торырга ярдәм итәргә тиеш.
22) Тарихи хәтер үстерү программасын төзү. Аерым алганда, татар милли шәхесләренә һәйкәлләр кую программасын, юл картасын булдыру.

**МЕДИА:**

23) Татар телендә фильмнар һәм мультфильмнар төшерү эшен активлаштыру. Моның өчен көндәшлек принципларына таянып бәйгеләр оештыру. Продукция сыйфатлы булу өчен финансның җитәрлек булуын исәпкә алу.
24) Дөньяда популяр булган видеоуеннар, компьютер уеннарын татар теленә тәрҗемә итү, популярлаштыру. Татар телендә смартфон кушымталарын булдыру эшен җайга салу.
25) Дөнькүләм популяр булган фильмнар, китапларны татар теленә тәрҗемә итү. Татар әдәбиятының күренекле үрнәкләрен урыс һәм инглиз телләренә тәрҗемә итү.
26) Татарча шәһәр мәдәниятен үстерү эшен дәвам итү. Альтернатив музыка, рәссамнар, дизайнерлар берләшәмәләре (сообщества), заманча сәнгать. Моны башка шәһәрләр, төбәкләргә дә чыгару, тарату.

**ТАТАРСТАННАН ЧИТТӘ ЯШӘҮЧЕ ТАТАРЛАР:**

27) Каюм Насыйри институтын татарлар күпләп яшәгән барлык төбәкләр һәм илләрдә ачу. Аның эшчәнлеген яңарту, заманча, сыйфатлы эшләүгә күчерү. .
28) Татарлар күпләр яшәгән төбәкләр һәм илләрдә татар теле курсларын даими үткәреп тору. Төрле тел чараларын оештыру (Юныс Әмрә үзәге мисалында).

29) Татарлар күпләп яшәгән шәһәрләрдә татар полилингваль мәктәпләрне ачу программасын төзү. Беренче чиратта, мондый полилингваль гимназияләр Уфа, Мәскәү, Төмән шәһәрләрендә ачылырга тиеш.